Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлегенең Болын-Балыкчы авылында гражданнар җыенының "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлегенең Болын-Балыкчы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм 2021 елда үзара салым кертү турында" 2020 елның 14нче ноябрендәге 1нче номерлы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлегенең Болын-Балыкчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш),1000 (бер мең) сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертүгә рөхсәт итәсезме »дигән мәсьәлә буенча 2020 елның 14нче ноябрендә Болын-Балыкчы авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

- Болын-Балыкчы авыл җирлегендә С. Сәйдәшев һәм М. Кәлимуллина урамында вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту;
- Болын-Балыкчы авылында су башнясы өчен насос һәм башка материаллар сатып алу;
- Болын-Балыкчы авыл җирлеге урамнарын яктырту (урамнарны яктырту, светодиод лампалар, чыгым материаллары сатып алу).

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 223 кеше кертелгән,җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 117 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенында катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 117 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Болын-Балыкчы авыл җирлегенең Болын-Балыкчы авылында халык җыенын узган,халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлегенең Болын-Балыкчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляска инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме дигән сорау буенча кабул ителгән карарны танырга һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Болын-Балыкчы авыл җирлегендә С. Сәйдәшев һәм М. Кәлимуллина урамында вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту;
- Болын-Балыкчы авылында су башнясы өчен насос һәм башка материаллар сатып алу;
- Болын-Балыкчы авыл җирлеге урамнарын яктырту (урамнарны яктырту, светодиод лампалар, чыгым материаллары сатып алу).

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлегенең Болын-Балыкчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 2021 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Болын-Балыкчы авыл җирлегендә С. Сәйдәшев һәм М. Кәлимуллина урамында вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту
- Болын-Балыкчы авылында су башнясы өчен насос һәм башка материаллар сатып алу;
- Болын-Балыкчы авыл җирлеге урамнарын яктырту (урамнарны яктырту, светодиод лампалар, чыгым материаллары сатып алу).

4.Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

**Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башлыгы:** **Фатрахманов М.И.**